# Россия Социаль фонды Татарстан бүлегенең коллегия утырышы: фондның 2025 елда эшчәнлеге нәтиҗәләре һәм 2026 елга бурычлар

Россия Социаль фондының  Татарстан бүлеге Идел буе федераль округында иң эреләрдән санала. Ел саен социаль  фонд бүлеге Республика халкына 1 миллионнан артык дәүләт хезмәте күрсәтә, шуларның 93%ы электрон форматта күрсәтелә. 2025 елда фонд хезмәтләреннән файдаланучы 1,1 миллионнан артык кеше пенсияләр һәм социаль түләүләрне үз вакытында һәм тулы күләмдә алды.

2025 елда бүлекнең контакт-үзәге операторлары тарафыннан гражданнарның 1,7 миллионга якын мөрәҗәгате эшкәртелгән. Хезмәт күрсәтү сыйфатыннан канәгатьлек дәрәҗәсе 97% тәшкил итте, бу әлеге хезмәтнең югары нәтиҗәлелеген күрсәтә. Эш бирүчеләр һәм эшмәкәрләр белән үзара хезмәттәшлеккә аерым игътибар бирелә: иминиятләштерүчеләр өчен кайнар линиягә хисап чорында 58,5 мең мөрәҗәгать кергән.

## Ана капиталы

Ана капиталы программасы балалары булган гаиләләргә ярдәм итүнең иң кирәкле чараларының берсе булып кала. Программаны гамәлгә ашыра башлаганнан бирле Татарстан Республикасында ана капиталы акчаларыннан 439 мең гаилә файдаланган. 136,3 мең сертификат проактив режимда бирелгән.

2026 елда ана капиталы индексацияләнде: беренче балага түләү 729 мең сумга якын, икенче бала өчен - 963 мең сум тәшкил итә.

Моннан тыш, 2025 елда Дагыстан Республикасында яшәүчеләргә ана капиталын рәсмиләштерү һәм түләү функциясе тулысынча беркетелде. Ике ел эчендә 60 меңгә якын гариза кабул ителде һәм 15 миллиард сумнан артык акча түләнде.

## Йөкле хатын-кызлар һәм яшь ата-аналарга ярдәм

Гаиләләргә ярдәм чаралары булачак әнинең йөклелек этабында ук күрсәтелә башлый. 2025 елда 24 меңнән артык хатын-кыз йөклелек һәм бала табу буенча пособие алган, гомуми түләүләр күләме 5,1 миллиард сум тәшкил иткән. Студентларга һәм аспирантларга түләүләр күләме сизелерлек артты - хәзер пособие региональ яшәү минимумы күләмендә билгеләнә.

26,4 мең ата- ана бала тугач 26,9 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган пособие алган. 54 меңнән артык гаиләгә баланы яшь ярымга җиткәнче карау буенча айлык пособие түләнде,  аның күләме эшләүче  ата-аналар өчен 10100 сумнан  68900  сумга кадәр тәшкил иткән.

2026 елда йөклелек һәм бала табу буенча пособиенең максималь күләме 1 миллион 324 мең сумга, ә эшләүче гражданнар өчен баланы яшь ярымга кадәр карау буенча пособие аена 83 мең сумга кадәр арттырыла.

## Бердәм пособие

Бердәм пособие, мохтаҗлыкны комплексы бәяләүне исәпкә алып,  балалары булган гаиләләргә һәм йөкле хатын-кызларга билгеләнә. 2025 елда түләү күләме бер балага

14,7 мең сумга якын,   авырлы хатын-кызлар өчен 16,4 мең сумнан артык тәшкил итте. Бердәм пособие түләүгә 26,7 миллиард сум акча юнәлдерелде.

## Пенсия ярдәме һәм өлкән буын турында кайгырту

2025 елда иминият пенсияләре 9,5% ка индексацияләнде. Иминият пенсиясенең уртача күләме 24,6 мең сумга җитте. Эшләүче пенсионерларның пенсияләрен индексацияләү яңартылды, ел саен август аенда узучы арттырулар сакланды.

2025 елда дәүләт тәэминаты буенча пенсияләр, социаль пенсияләрне дә кертеп, 14,75% ка индексацияләнде, әлеге арттыру  85 меңнән артык кешегә кагылды. Пенсияләр составына I төркем инвалидларны һәм 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнарны карау буенча өстәмә түләүләр кертелгән, алар автомат рәвештә билгеләнә.

2026 елның 1 гыйнварыннан иминият пенсияләре 7,6% ка индексацияләнде. Социаль пенсияләр 1 апрельдән пенсионерның яшәү минимумы артуны исәпкә алып арттырылачак.

Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгы уңаеннан  Ватан сугышы ветераннары 80 мең, тыл хезмәтчәннәре 55 мең сум күләмендә бер тапкыр түләнә торган түләү алдылар.

## Вакытлыча хезмәткә яраксызлык буенча пособие

Вакытлыча хезмәткә яраксызлык кәгазьләре тулысынча электрон рәвештә рәсмиләштерелә. 2025 елда вакытлыча хезмәткә яраксызлык буенча пособиеләр түләүгә 18,6 миллиард сумнан артык акча юнәлдерелгән.

2026 елдан башлап социаль иминият системасында үзмәшгульләр  өчен яңа гарантияләр барлыкка килә -  үз теләкләре белән иминият кертемнәрен  түләгән очракта алар  вакытлыча хезмәткә яраксызлык чоры өчен пособие ала алалар.

## Инвалидларны реабилитацияләүнең техник чаралары һәм аларга ярдәм

2025 елда Татарстан Республикасында гражданнарны реабилитацияләүнең техник чаралары белән тәэмин итүне финанслау күләме 3,5 миллиард сумга якын тәшкил итте. Акчаларның төп өлеше тернәкләндерү чараларын тизрәк һәм уңайлырак алырга мөмкинлек бирә торган электрон сертификатлардан  файдалануга юнәлтелгән.

2026 елның 1 гыйнварыннан Татарстан инвалид балаларны электрон сертификаттан файдаланып комплекслы тернәкләндерү һәм реабилитацияләү буенча пилот проектында катнаша.

## Махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм

Махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаиләләренә ярдәм итү бүлек эшчәнлегенең өстенлекле юнәлеше булып кала. Барлык түләүләр һәм ярдәм чаралары проактив режимда билгеләнә. Хезмәт итү еллары стажга икеләтә күләмдә кертелә.

Демобилизацияләнүчеләр медицина реабилитациясе һәм шифаханә-курорт дәвалануыннан файдалана, хәзер аларны озата баручы  туганнарына яшәү, туклану һәм юл йөрү чыгымнары  түләнә.

## Цифрлаштыру һәм клиентны кайгырту

Россия социаль фондының Татарстан Республикасы бүлеге цифрлы сервисларны үстерүне дәвам итә. 2025 елда дәүләт хезмәтләренең 93%ы электрон рәвештә күрсәтелде.

Татарстан Россиядә социаль фондның флагман клиент хезмәте ачылачак беренче төбәк булачак, ул 2026 елда Казанның Вахитов районы клиент хезмәте базасында эшләячәк.

2026 елда шулай ук яңа мәгълүмат форматларын: MAX кушымтасындагы бүлекчә каналы, «СФР в деталях» подкастасы һәм онлайн-проектлар сериясен эшләтеп җибәрү планлаштырыла.

Россия социаль фондының Татарстан Республикасы бүлеге республика халкы өчен ышанычлы партнер булып кала бирә. 2026 елда Фонд игътибарын цифрлы сервисларны үстерү, хезмәт күрсәтү сыйфатын яхшырту һәм барлык категориядәге гражданнарга социаль ярдәм күрсәтүне артыруга юнәлтәчәк.